# ЧЫН ТЕАТР МӘКТӘПТӘН БАШЛАНА

Мәктәп чоры — кеше күңелендә гүзәл хатирәләр калдыра торган вакыт. Кан кайнап, дәрт ташып торган чакта җырлыйсы, биисе, спектакль уйныйсы килә. М. Фәйзинең «Галиябану»ы, Г. Камалның «Беренче театр»ы кебек классик әсәрләр һәр мәктәп сәхнәсендә куелгандыр, мөгаен. Шулай да яңаларын, нәкъ үз яшьтәшләрең турындагысын сәхнәләштерү кызыграк. Нәшриятыбызда әлеге пьесалар җыентыгын әзерләүнең сәбәбе дә шул.

Әсәрләрне туплаганда авторның каләм көченә һәм балалар күңелен аңлый белүенә игътибар бирдек. Китапка Разил Вәлиев, Нәбирә Гыйматдинова, Галимҗан Гыйльманов, Рафис Корбан, Нурия Сәйяр, яшьләрдән Илгиз Зәйниев, Раилә Мөхсиноваларның пьесалары керде. Шулай да аның Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әсәре белән башланып китүе табигый. Чөнки безнең балалар сәхнәсе дә чын мәгънәсендә шушы әкиятне кую белән башланып китмәдеме икән әле.

Абдулла Алиш пьесасы әкият вариантыннан сюжеты белән дә, үзенчәлекле теле белән дә аерылып тора. Монда, әкияттән аермалы буларак, төлке авызына эләккән Сертотмасның исән калуы гаҗәп. Шулай ук пьесаның шигъри теле дә аерым игътибарга лаек, бу рәвешчә әсәр үзенчәлекле төсмер ала.

Разил Вәлиевнең «Шомбай маҗаралары» кызыклы сюжетка корылган. Төрле әкиятләр каһарманнары бер-берсенең язмышы өчен борчылып, бер-берсенә ярдәм итәргә әзер тора. Исеменнән үк күренгәнчә, драманың төп герое Шомбай үзенең иптәшләрен эзли. Татар халык әкиятендә үткен, үз максатына ирешә торган акыллы егетне автор да шул килеш саклаган. Мәгълүм әкияттән аермалы буларак, Шомбай — бүгенге чор кешесе. Ул мотоциклда да йөри, фән-техника казанышларыннан да хәбәрдар, кесәсендә пистолет та йөртә. Шундый каһарман булуы әсәрне америка блокбастерларына охшатып җибәрә. Автор шулай ук хатын-кыз психологиясен дә уңышлы ача. Шомбай Су кызына Убыр патша тоткынлыгыннан үзе генә качарга кушкач, кыз: «Юк-юк, мин сине ялгыз калдыра алмыйм, бергә үләбез», — ди.

Шунысы кызык: Тукай әсәрләрендә уңай каһарман булган Былтыр монда — тискәре, тискәре герой булган Шүрәле уңай яктан ачыла. Дөрес, Былтыр соңрак барыбер туры юлга кайта, ләкин бөтенесенең дә шулай асты өскә килү тамашачыны гаҗәпләндерә. Разил Вәлиев шул ук Былтыр, Алдар малайише бизнес вәкилләренең дә психологиясен уңышлы җиткерә алган. Әсәрдә файда артыннан гына куган бүгенге заман байларының җәмгыятьтәге төрле проблемаларга битараф булуы да чагыла. Маңгаена пистолет терәгәч, аларның шапырынуларының юкка чыгуы, коелып төшүләре, асылда, куркак булуларын ачып сала. Әлбәттә, үлем куркынычы янаганда сирәкләр генә батыр булып каладыр, әмма әкиятләрдә ни генә булса да, өркеп калмаган

батырларны еш күрәбез, чөнки аларның хакыйкать тарафында булуы, кимсетелгәннәрне яклавы рухи көч бирә, алар авырлыкларда да сынмый, сыгылмый.

Халык әкиятендәге Шомбайның гади генә юл белән, киеменең кире ягын киеп, икенче кеше булып күренергә тырышуын автор үстереп җибәрә, тылсым көче өсти. Урынында бер әйләнеп, бандит, шүрәле, су кызына әверелүе әсәрне кызыклырак итә. Шулай да автор фольклордан алынган сюжетлардан бөтенләй үк баш тартмый. Убыр патша куган вакытта, Шомбай тарак, көзге ташлап, арада урман, диңгез барлыкка килүе пьесаны халыкчан итә. Автор экология проблемаларын гына түгел, ә атом-төш коралларының дәһшәтен, тирә-юньгә битараф булуның куркынычлыгын күрсәтергә тели. Әнә шул Былтырлар, Алдар малайлар вакытында игътибарлырак булсалар, бәлки, Убыр патша шүрәлеләрне, су кызларын җыеп урлап китә алмас иде.

Гомумән, тәрбияви дә, маҗаралы да әлеге әсәрне сәхнәгә куюы балалар өчен дә, тамашачылар өчен дә кызыклы булачак.

Галимҗан Гыйльмановның «Булат нигә яхшы укый?» пьесасы да сәхнәгә кую өчен бик уңышлы, чөнки катнашучылар да аз, нибары дүрт кенә каһарман, авыр декорацияләр дә сорамый. Сюжеты да мәктәптә укучы балалар тормышы белән тыгыз бәйләнгән. Автор, мифология белгече буларак, татар халкында балаларны куркыта торган йорт иясе — Бүкәй образын дөньяга чыгарган. Бүкәй дә ниндидер тылсымлы зат түгел, ә нәкъ Булат кебек гади генә бер малай икән. Шулай да гайре табигый бер ягы бар аның — тиз генә теләсә нинди мәсьәләне чишә дә бирә. Икенче яктан карасаң, тиз исәпли белү ул кадәр шаккаткыч күренеш тә түгел. Әнә күрше кызы Әдилә дә математикадан Булатка ярдәм итәргә әзер, уку ягыннан да проблемалары юк.

Галимҗан Гыйльманов мәктәп баласының холкын оста ача. Булат өй эшләрен үзе эшләргә тырыша, Әдиләнең ярдәм итәргә теләвен гел кире кага. Әдилә малайны үзен ошатып бетерми, шуңа кире кага дип борчыла, ә Булатта чын ирләр психологиясе — кызлардан акыллырак, өстенрәк булырга теләү.

Автор диалогларны аеруча оста төзи. Малайлар-кызларның сөйләшүе дә хиссирәк, җөмләләре дә кыскарак. Бу табигый да, чөнки балалар тормышы хискә бай, бөтен хисләрне сүз белән аңлатып торырга мөмкинлекләре дә юк.

Нәбирә Гыйматдинованың «Аю килгән бәйрәмгә» пьесасы — Яңа ел кичен үткәрергә менә дигән сценарий. Анда Аю белән Бүре арасында хакимият өчен көрәш тә, хәйлә дә, кече күңеллелек тә бар. Кыш бабайның капчыгын урлап киткән Бүренең азакта үзе уңайсыз хәлдә калуы һәркем өчен гыйбрәт. Яңа ел бәйрәмендә күп балаларны катнаштырырга да мөмкинлек бирә.

Әсәрнең каһарманнары — җәнлекләр. Әдәбиятыбызда кабул ителгәнчә, монда да Бүре явыз, Төлке хәйләкәр, Куян — яңа фикер әйтүче. Урмандагы җәнлекләрнең Аюны ихтирам иткән булып, аңа ялагайланырга тырышуы да мәзәк күренә. Хакимият өчен көрәшсә дә, Бүре Аюга каршы барырга базмый. Автор балаларга җәмгыятьнең төзелешен аңлата һәм хакыйкатьнең һәрвакыт өстен чыгуын күрсәтә.

Илгиз Зәйниевнең «Кәҗә, Сарык һәм башкалар» комедиясе аерым игътибарга лаек. Сәхнәнең бөтен нечкәлекләрен белеп язылганы күренеп тора. Әсәрдә җор теллелек бик югары дәрәҗәдә. Пьесада Габдулла Тукайның бөтен әкиятләреннән килеп кергән каһарманнар, аларның бер-берсе белән аралашуы — Илгизнең зур табышы. Төп каһарманнар — Кәҗә белән Сарык. Сюжеты һәркемгә мәгълүм булса да, сәер эпизодик геройларның арага килеп керүе, балаларның күптәнге хыялы булган Шүрәле белән Су анасын кавыштыру, әллә каян килеп кергән Күк Сыер, кызыклы шәкерт Акбайның мактанчыклыгы аерым бер төсмер бирә.

Әсәр балаларга дуслыкның кадерен белергә өйрәтә. Автор кешедәге үз-үзеңне генә ярату, артык горур булу кебек тискәре сыйфатның аянычлы нәтиҗәләргә китергәнен Күк Сыер мисалында аңлатып китә, балаларны ярдәмчел булырга, батыр булырга өнди.

Пьесаның теле дә нәкъ мәктәп балалары сөйләшкән телдә, шуңа күрә әсәр балаларга якын. Мәктәп укучылары комедияне бик яратып уйнар дип ышанабыз. Укытучылар да Г. Тукай иҗатына экскурс ясауны хуп күрерләр, минемчә. Җыеп әйткәндә, мәктәп сәхнәсе өчен бик кызыклы вә уңышлы дип саныйм.

Рафис Корбанның «Бүре һәм Кәҗә» әсәре барыбызга да мәгълүм бертуган Гриммнар эшкәрткән «Бүре һәм җиде кәҗә бәтие» исемле алман халык әкиятенә барып тоташа.

Пьесаның шигъри тел белән язылуы рольләрне ятлауны җиңеләйтә. Сюжеты барыбызга да таныш. Драманың нигезендә «балалар, бу дөньяда хәйлә, мәкер бар, шуңа юлыгып авыр хәлдә калмагыз» дигән фикер ята. Автор хакыйкатьнең һәрвакыт өстен чыгуы, явызлыкның барыбер җиңеләчәгенә ышаныч уята. Бертуган Гриммнар сюжетында учакта яндырылып үтерелгән Бүредән аермалы буларак, Рафис Корбан Бүрегә каты җәза бирми, дошманны бөтенләй юкка чыгармый, балаларны явызлык эшләгән бәндәләрне кичерергә, һичьюгында, үч алмаска өйрәтә.

Р. Корбанның шигъри теле төгәл, нәфис һәм «җырлап тора торган». Пьесага ярар әле дип, сыйфат түбән төшерелмәгән, ә югары шигъри кимәлдә язылуы шагыйрьнең талантын һәм әсәргә карата җитди мөнәсәбәтен күрсәтә.

Раилә Мөхсинованың «Практикантлар килгән безгә...» пьесасында югары сыйныфларда укучы «борыннарына кызлар исе керә башлаган» егетләр, көязләнеп йөрергә ярата торган кызлар белән очрашабыз. Гадәттәгечә, укуга теләге булган балалар аз. Альберт белән Лилия генә чын мәгънәсендә белем алырга телиләр. Рәзил, Алмаз, Эльвира, Ралинәләрне иң яхшы мәктәптә укытсаң да, күңелләрен укуга бирмәсләре көн кебек ачык. Ә йокларга яратучы Илсаф — аерата кызык персонаж. Пьесаны сәхнәгә куйганда да аның ролен уйныйсы җиңел булыр. Андый кешене күргәнем булмаса да, әлеге каһарманны авторның зур табышы дип саныйм.

Алия Әхәтовна персонажы да кызыклы гына ачылган. Ул гадәти студент кыз кебек беркатлы, идеалист, хыялыйрак, ләкин 9 нчы «Б» сыйныфына килеп керү аны тиз арада җиргә тартып төшерә. Шунда җыештыручы булып эшләгән бик хикмәтле

Сәрия апа булмаса, практикант кыз бөтенләй үз эшен, укуын ташлаган булыр иде, мөгаен.

Үсмерләрнең үзара сөйләшүе дә табигый тел белән язылган. Ниндидер махсус күпертү, артык пафос юк. Шул ягы белән әлеге әсәр мәктәп тормышына тагын да якынрак. Карап торышка битараф егетләр кызларны уятып җибәрергә әнә шул Сәрия апаларының дәрес бирүе дә җитә икән. Рәзил, Алмаз, Эльвира, Ралинәләрнең дә кинәт үзгәрүе бер яктан шаккатырса, икенче яктан шатландыра. Укытучыны ихтирам итәргә аларны җыештыручы Сәрия апа өйрәтүе дә кызык. Балалар да практикант кызны аңлый, аны кызгана, хәленә керә башлыйлар.

Нурия Сәйяр иҗат иткән «Хикмәтле кыңгырау» да мәктәп тормышына бик якын, әмма монда төп проблема булып экология, кош-кортларга, җәнлек-җанварларга кырыс мөнәсәбәт мәсьәләсе. Мәктәптә аңлатып торуларына карамастан, укучылар һаман хайваннарны рәнҗетә. Проблеманы яхшырак аңлату өчен автор бакаларны һәм карганы кешеләштерүне хуп күргән. Шулай иткәндә, тамашачылар да җәнлекләрнең хәлен якыннанрак аңлый.

Әсәрдә төп каршылык Дамир белән мәктәп арасында. Дамирның укырга керәсе килә, ә аны яшең җитми дип алмаска итәләр. Әлеге хәлдән күңеле сүрелгән Дамир, Карга һәм бакалар белән килешүгә бара: аларның теләген үтәп, кыңгырауны алып кача. Әлбәттә, бу гамәлне автор акларга теләми, ләкин малайның мәктәпкә керү теләге көчле икәнен шулай итеп күрсәтә ул. Дамирның әйбәт малай икәнен Гөлнара: «Ичмасам, Дамир да безнең белән бармый, шул сугыш чукмарларыннан яклар иде», — дип, иптәш кызына әйтеп куюыннан аңлыйбыз, хайваннарның хәленә керә белүе дә хуп. Шуңа да карамастан Дамир — каршылыклы персонаж. Бер яктан ул үз максатына ирешер өчен теләсә нинди юлга әзер сыман, икенче яктан ул — кече күңелле, ярдәмчел малай.

Пьесадагы әлеге ике мәсьәлә дә чишелә. Директор ханымның шәхсән бакалар белән сөйләшүе, җәнлекләрнең дә Дамирны мактавы ике проблеманы да хәл итә. Мәктәп мөдире балалар да күлне чистартырга ярдәм итәр, бакаларга да бүтән зыян салынмас, Дамирны да мәктәпкә алабыз дип игълан итә.

Әсәр балаларны табигатькә игътибарлы булырга чакыра. Кош-кортлар да безнең кебек үк җан ияләре, аларга битараф булырга ярамый дигән фикер алга сөрелә.

...Мәктәптә уку — шәхеснең дөньяга карашы формалашкан бик мөһим чор. Укучыларда туган телебезгә, туган илебезгә мәхәббәт уятыр, дөньяда үз урынын табар, башкаларның хәленә керә белер, аларны аңлар өчен спектакльләрдә катнашып яки аларны карап гыйбрәт ала белергә тиеш. Чын театр мәктәптән башлана!

*Рифат Сәлах*

**Абдулла Алиш**

# СЕРТОТМАС ҮРДӘК

*Бер пәрдәле, биш күренештән торган әкият-пьеса*

## КАТНАШАЛАР:

Алып баручы.
Аучы.
Актырнак – Аучының эте.
Сертотмас – үрдәк.
Керпе.
Куян.
Бүре.
Аю.
Төлке.
Төлке балалары.
Әтәч.
Сарык.